# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

1 статья. «Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә табигать иркендәге шартларда яшәүче хайваннар дөньясы объектлары анын дәүләт милке була, моңа федераль милеккә кертелгән хайваннар дөньясы объектлары керми.»;

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясына дәүләт милкен федераль һәм республика милке итеп чикләү федераль закон билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

2. 7 статьяның 1 өлешендә:

2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкенә керүче хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны җайга салу;»;

4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкенә керүче хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга лицензияләр бирү;».

3. 8 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясы объектларының дәүләт исәбен һәм дәүләт кадастрын алып бару федераль законнар билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

4. 9 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясы объектларының дәүләт мониторингын алып бару федераль законнар билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

5. 12 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге хайваннар дөньясының аерым объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм торгызу максатларында, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану төрен үзгәртергә, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны чикләргә, туктатып торырга һәм бөтенләй тыярга мөмкин.».

6. 14 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли табигать паркларының тыюлык зоналары территорияләрендә хайваннар дөньясының үз бурычларына туры килми торган файдалануның барлык төрләре, шулай ук кыргый хайваннарның яшәү тирәлеген үзгәртүгә китерүче теләсә нинди эшчәнлек законнар билгеләгән тәртиптә тыела.»;

5 өлешне төшереп калдырырга.

7. 20 статьяның 2 өлешен төшереп калдырырга.

8. 21 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

9. 22 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге хайваннар дөньясының табигый яшәү тирәлегеннән лицензиясез аерып алу тыелган объектлары исемлеге Татарстан Республикасының хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану (махсус куллану) өлкәсендәге махсус вәкаләтле органнары тарафыннан билгеләнә.».

10. 23 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

11. 24 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясының аулау объектларына кертелгән объектларының исемлеге федераль законнар билгели торган тәртиптә төзелә һәм раслана.».

12. 27 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге хайваннар дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияви, рекреация һәм эстетик максатларда хайваннар дөньясы объектларын табигый тирәлектән аерып алып файдалану Татарстан Республикасы Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгының билгеләнгән тәртиптә бирелүче рөхсәте буенча башкарыла.».

13. 29 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге хайваннар дөньясы объектларыннан аларның тереклек эшчәнлеге продуктларын алу максатларында файдалану кагыйдәләре Татарстан Республикасының хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан билгеләнә.».

14. 33 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр системасы федераль законнар белән билгеләнә.»;

3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләү федераль бюджетка һәм Татарстан Республикасының республика бюджетына федераль закон билгеләгән тәртиптә кертелә.».

15. 7 бүлекне төшереп калдырырга.

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 22 феврале
№ 648